ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**14 ноябрь 2019 ел** **№ 843**

“2020 елга «Ютазы муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-
эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында
өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
чыгымнар нормативын раслау турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 ел, 14 декабрь, №854 карары һәм «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга:

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелгән чыгымнар нормативын;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 0,5 күләмендә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Ә. Шафигуллин

А.В. Сучкова
2-80-12

Утверждены
Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланды
«____» ________ 20___ ел № ____

**"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә ЧЫГЫМНАР НОРМАТИВЫ**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Урнашкан урыны | Чыгымнар нормативы (елга бер укучыга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өч еллык уку срогы | Дүрт еллык уку срогы | Биш еллык уку срогы | Җиде еллык уку срогы | Иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | Шәһәр җире | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | Авыл җире | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Рәсем сәнгате | Шәһәр җире | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Рәсем сәнгате | Авыл җире | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | Шәһәр җире | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | Авыл җире | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җире | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җире | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җире | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | Авыл җире | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җире | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җире | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җире | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | Авыл җире | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |